ГЛАВА УРАЗБАХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.1а, с. Уразбахтино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422155

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗБАХТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 1 нче а йорт, Уразбахты авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422155

тел.(факс): (85563) 2-86-36; e-mail: UrBah.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар | Постановление

“25 ”октябрь 2019 ел | № 5

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Уразбахты авылы , Совет урамы , 1 нче В йорт адресы буенча урнашкан Уразбахты авылы мәдәният йорты бинасында 2019 елның 7 нче ноябрендә сәгать16.30 да Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү ) Җиңү урамы, Уразбахты авылы;
- Уразбахты авылы урам юлларын кардан чистарту;
- җәй көне Уразбахты авылында юлларны кырдырып тигезләү;
- су кудыру системасын алыштыру (чишмәдән башняга су агызу өчен 3 кое казу, материаллар сатып алу, ташу, урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү) Уразбахты авылы;

« ӘЙЕ»　　　　«ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге башкарма комитетына Уразбахты авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге башлыгы:　　　　Р.Г.Шәйхетдинов